В.М. Усманов

Татарстан Республикасы Ютазы районы эпиграфик һәйкәлләре

Егерменче китап

Казан – 2024

ББК 63.4 (2Рос = Тат)
УДК 902
У 74

Китап авторның үз хисабына нәшер ителә.

Я, Венер Мударисович Усманов, являющися автором этого издания даю полное согласие на использование моих личных фотоснимков и прорисовок размещенных в этой книге в учебных, научных и коммерческих целях без моего письменного разрешения со сылкой на первоисточник.

Усманов В.М. Татарстан Республикасы Ютазы районы эпиграфик һәйкәлләре. – Егерменче китап. – Казан, 2024. – 418 б.: рәс. белән.

Бу (егерменче) җыентыкта 1767-2020 еллар арасында Ютазы районы биләмәләрендә сакланып калган ташъязма ядкәрләрнең рәсем-күчермәләре кыскача мәгълүмат белән каталог рәвешендә бирелде.

Китап сәнгать белгечләре һәм тарих белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Предлагаемое издание является сводом татарских эпиграфических памятников Ютазинского района Республики Татарстан в виде каталога. На сегодняшний день данная книга представляет из себя наиболее полное издание, где собраны более двухсот артефактов богато представленных фотоматериалами и прорисовками с сопровождающими краткими текстами.

Книги адресована специалистам в области эпиграфики, искусствоведам и всем интересующимся историей и культурой татарского народа.

© Усманов В.М., 2024

ЮТАЗЫ ТӨБӘГЕНЕҢ ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Книга посвящена исследованию сохранившихся эпиграфических памятников на мусульманских кладбищах сел Ютазинского района. В результате проведенной экспедиции было выявлено и зафиксировано более двухсот арабографических артефактов. Основная часть кабрташей выполнены из местных непрочных песчаников, которые под воздействием отрицательных природных факторов отслаиваясь легко разрушаются, выветриваются и уходят в небытие. И поэтому, при таких обстоятельствах, есть неотложная необходимость сохранения сведений “каменного архива”, хотя бы путем составления свода эпиграфических памятников в виде каталога с последующей публикацией для введения в научный оборот в наиболее полном объеме.

Более 80 % информации мы получаем через зрительные органы. А в эпиграфике главным носителем информации является сам объект, в данном случае, фотографии соответствующего качества, оттиски, эстампажи или прорисовки. В связи с этим, как архиважное приложение к данной статье предлагаются графические изображения – иллюстрации.

2023 елның 18 сентябреннән алып 27 сентябрь көннәренә кадәр Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел , әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан Ютазы районындагы татар авылларына комплекслы фәнни экспедиция оештырылган иде. Барып кайтуларның максаты – бу якларда сакланып калган мәдәни ядкәрләрне һәм шул исәптән эпиграфик һәйкәлләрне дә исәпкә алу иде. Ютазы төбәгендәге татар кабер ташлары, фәнни чыганак буларак, М. Әхмәтҗанов, А. Борһанов, Җ. Мөхәммәтшин, М. Закирова, А. Ибраһимова, Ә. Хаҗиева һ. б. тарафыннан күпмедер күләмдә өйрәнелгән.

Иң борынгы истәлекләрдән Иске Урыссу (Ырыссу) авылы янәшәсендәге калкулыкта X-XII гасырлардан торып калган ике балбал – “Таш хатын” сыннарының булуы мәгълүм. Кызганычка каршы алар 1940-1960 елларда җимерелеп юкка чыкканнар.

Ташъязма истәлекләрдән, бу төбәкнең иң әүвәлгеләре – Иске Ырыссудагы Муса кызы Зөһрә һәм Бәйрәкәдәге Йосыф Котлыгмөхәммәд угылы Тәфкилев каберләренә 1767 һәм 1773 елларда куелган гүрташлары (китабәләр). Чагыштырмача, ташъязмаларга бай зиратлар Бәйрәкә, Иске Урыссу (Ырыссу) һәм Кәрәкәшле авылларында урнашкан. Сакланып калган әүвәлге кабер ташларының саны аерым авылларда түбәндәгечә бирелде.

1. Акбаш авылы – 22 (ташъязма),
2. Акъюл авылы – 7,
3. Байлар авылы – 0,
4. Бәйрәкә авылы – 29,
5. Бәйрәкә Тамак авылы – 3,
6. Дим Тамак авылы – 7,
7. Әбсәлям авылы – 7,
8. Иске Каразирек авылы – 11,
9. Иске Ырыссу авылы – 40,
10. Кече Ырыссу авылы – 4,
11. Кәрәкәшле авылы – 26,
12. Көрәш Бүләк – 3,
13. Колчан авылы – 1,
14. Салкын Чишмә авылы – 0,
15. Ташкичү авылы – 8,
16. Ырыссу авылы – 8,
17. Ютазы авылы – 19,
18. Яңы Каразирек авылы – 19,
19. Яссы Тугай авылы – 12,

Китабәләрнең күп өлешен төгәл кем язганлыгы мәгълүм түгел, вәләкин, шунысы аңлашыла – аларның шактыен урындагы укымышлы кул

осталары (еш очракта, дин әһелләре) башкарган. Эпитафияләрнең кайберләре, авторлары безгә төгәл мәгълүм булмаган ташъязмалар чит тарафтан ясалып китерелгән (мәсәлән, 161,176 саннары белән каталогта беркетелгәннәре) һәм моның ише үрнәкләр әлеге Башкортстан һәм Татарстан чикләрендәге районнарда еш очравы күзәтелә. Кабер ташларының бер өлеше (мәсәлән, 43, 46, 59, 60, 62, 65, 66, 113, 118, 161, 176, 198, 201 номерлылары) профессионал "таш язгучы" осталар тарафыннан башкарылган, шуларның бер-ничәсе гади кятиб кенә түгел ә, чын дәрәҗәсендә хаттат дип саналырга хаклылардыр. Кайбер кятибләр ташларда үзләренең исем-шәрифләрен дә уеп-язып калдырганнар, мәсәлән: "*Ошбуны яздым Габделҗәлил*" (Акбаш авылы, 1 нче таш), "*Кятиб Гали бине Мөхәммәдсадыйк*" (Акбаш, 8 нче таш, һәм Дим-Тамак авыллары, 94 нче таш), "*Кятиб Зыяддин бине Хисамеддин, Чупай карьясе*" (Бәйрәкә авылы, 66 нче таш), "*Ошбуны язучы Шәрифулла*" (Акбаш авылы, 15 нче таш), "*Кятиб Хәсән*" (Ташкичү авылы, 214 нче таш). Эш барышында, соңгы дәвердәге осталарның да исемнәрен язып ала бардык, шулардан: Заһид Инсаф улы Фәттахов (1951-2005), 8 нче таш (Акъюл авылында), Наиль Кави улы Фәттахов (Акъюл авылында).

Ташъязма ядкәрләрнең күб өлеше урындагы карьерлардан (тау башларыннан, елга буйларыннан) чыгарылган "өлгереп җитмәгән" йомшак һәм уалып барган комташлардан ясалган, шул сәбәпле эпитафияләрнең бер өлеше җуелып юкка чыккан яисә бик начар хәлдә сакланып кала алган. Монардан башка, аларның шактые, катлам-катлам аерылып һәм ярылып җимерелә бара. Арасында, нык һәм каты комташлар да бар, еш очракта, аларны шомартып, нечкә генә хәрефләр белән чыеп язганнар, шуның ише үрнәкләр дә еш очрый.

Фараз итүләр буенча, кайбер известьташлар Әлмәт ягындагы Чупай карьерыннан китерелгән, мәсәлән, Зыятдин кятиб кулы белән рельефлы (калкытып) язылган 66 нчы нумерлы китабә. Ядкәрләр арасында затлы ташлардан (мәрмәрдән яисә граниттан) Троицк, Оренбург (Каргалы) Казан, Чистай яисә Буа шәһәрләрендә ясалганнары безгә күренмәде.

Кайбер кабер ташларында нәсел тамгаларын очратырга мөмкин, вәләкин, бу сирәк күренеш, гомумән, бу төбәктә моның кебек борынгыдан килгән ыру билгеләрен начар хәтерлиләр.

Күп кенә зиратларда кабер өсләрен бура яисә кыргый ташлар белән уратып алынганнары да бар, алар күп булмаса да, андый үрнәкләрнең кайберләре безнең көнгә кадәр сакланып кала алган (187).

Ютазы ягындагы мазарстаннарда гүр ташы урынына имән агачыннан ясалган кабер казыгы урнаштыру очраклары да бар, бу төбәктә аны башказык дип атап йөретәләр (26). Күрәсең, борынгы заманнарда, мондый гади башбаталарга нәсел тамгалары уелып ясалган булгандыр (10, 11, 19, 23, 25, 77,115,141). Хәзерге көннәрдә башказыкның киртләп алынган өлешендәге яссылыкка мәрхүмнәрнең исем-шәрифләренең баш хәрефләрен кисеп язганнар (278). Күпмедер вакыт үтү белән (мадди мөмкинчелектән чыгып) башказыкның янәшәсенә язулы кабер ташы да куелган. Соңгы бер-ничә дистә ел дәвамында мәрхүмнәрнең портретларын мәрмәр ташларга ясап, кабер өстенә веноклар кую кебек читтән керә барган гадәтләр дә өстенлек ала башлаган. Китабәләрдәге язуларның кайберләре тимер калайга (пластинкага) язылып чардуганга беркетелеп куелганнары да еш очрый.

Аңлашыла ки, борынгы яисә элекке гүр ташлары гарәп язуында башкарылган һәм ул традиция өзелмичә безнең көннәргә кадәр сакланып кала алган. Дөрес, хәзерге вакытта, каберташларындагы текстларның төп өлеше тулысынча кириллица хәрефләре белән татарча башкарыла. 1929-1940 еллар арасындагы язма ядкәрләрнең латин хәрефләре белән башкарылганнары да бар. Эпитафияләрнең күп өлеше уеп яисә чыеп язылган, вәләкин, иң күркәм композицияләрнең күп өлеше калкытып язу ысулы белән рельефлы рәвештә язылган. Гадәттә, татар осталары гарәп хәрефләренең кырларын кыек рәвештә кисеп язганнар һәм бу алымнар ташъязмалардагы бизәкләрне төрле төсмерләргә баетып вә сыгылмалы сызыклар ыңгаена салып сәнгати әсәр тудырырга тырышканнар. Китабәләрдә гадәттә татарча шигъри юллар да язганнар, вәләкин бу төбәктә андый үрнәкләр күренмәде.

Ташъязма истәлекләр

№ 1

[**Ишкенә**] каберенә куелган таш. Акбаш авылы, 1 нче зират.

“Ошбуны яздым Габделҗәлил”

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ لا جعل ايشكنه ۞ اوشبونى مين يازدم عبدالجليل ۞

Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.

№ 2

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш. Акбаш авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ ... [قزى]... ۞

Бисмилләһир ир-рахман ир-рахим– рәхимле, шәфкатле Аллаһның исеме белән.

№ 3

Габдерр… каберенә куелган таш. Акбаш авылы, 1 нче зират.

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ عبد ال... ۞

№ 4

[**... Җиһан**] каберенә куелган таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ ا... [جهان] ۞

№ 5

Фатиха каберенә куелган таш. 1097 нче һиҗри сәнә / 1685 нче милади ел.

۞ ١٠٩٧ يلده ۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ الشهد ان... ۞ ببى فاتحه ۞

Әгузе билләһи минәш-шәйтанир-ражим[1]

№ 6

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш. [1888] нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ ... ۞ ١٨٨٨ ۞

№ 7

[Габделхалим] кызы каберенә куелган таш. 1884 нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ عبد... بن شريف الله ۞ ... اوعلى يازدرب ... ١٨٨٤ ۞

№ 8

Хәбибулла бине Гыйззәтулла каберенә куелган таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ ... ۞ صا حيب .... حبيب الله بن عزت الله ۞ كاتيب على ۞ بن محمد صاديق ۞

“**Кятиб Гали** бине Мөхәммәдсадыйк”

№ 9

[Мөхәммәдшаһ] каберенә куелган таш. 1884 нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ ... محمد شاه ۞ يا الله ... ۞

№ 10

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 11

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 12

Бибифәхри [Аетбай] кызы каберенә куелган таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ ببى فحرى [ايتباى] قزى ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞

---

[1] *Әгузе билләһи мин әш-шәйтан ир-ражим* - Куылган шайтанның явызлыгыннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам (сыенам).

№ 14

Бибиҗәмал бинте Габделҗәббар каберенә куелган таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ ببى جمال بنت عبد الجبار ۞

№ 15

[**Сахибҗәмал** Габделгалим] кызы каберенә куелган таш. 1881 нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

"Ошбуны язгучы [**Шәрифулла**]

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ اشهدان لا

اله الاالله و اشهدان محمدا عبده و رسوله ۞ صاحب كمال عبد عليم قزى اوشبونى

يازعوچى شر[يف] الله [عبد الحكيم] ۞ اوعلى ١٨٨١ يلده ۞

әшһәдү әл-лә иләһә иллә Аллаһу вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү вә расүлүһә[2]

№ 16

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш. [1900] нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 17

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 18

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 19

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 20

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

---

[2] Кәлимәи шәһадәт: бер Аллаһтан башка илаһи зат юклыгын һәм Мөхәммәд аның илчесе булуын таныйм.

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ ... اوش... ۞... الا... ۞... ۞

№ 21

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ ... كارى ... ۞ ... اوعلى ... ۞

№ 22

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ عزل ش ... ۞

№ 23

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 24

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 25

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 26

Кемнең каберенә куелганы билгесез башказык. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 27

Кемнең каберенә куелганы билгесез язулы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 28

Кемнең каберенә куелганы билгесез язулы таш. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ [١٩١٥ نچى يل] ۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله... ۞...محمد... ۞

№ 29

Мөхәммәдәмин Мөхәммәдрәхим углы каберенә куелган таш. [1915] нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ ١٩١٥ نچى يل ۞ محمد امين محمد رحيم اوعلى ۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ اشهدان لا الله الا الله اشهدان محمدا عبده و رسوله ۞

№ 30

[**Гали**] каберенә куелган таш. 1920 нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله... ۞ ۱۹۲۰ سنه وفات بولدی [علی]... اوعلی یازب... ۞

№ 31

Фәттах Кәшшәфетдин Минлекәев каберенә куелган таш. 1883-1921. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 32

[**Вәли**] каберенә куелган таш. 1923 нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ [ولی] ۞ ۱۹۲۳ ۞

№ 33

[**Миңлежәмал** Гәрәй кызы] каберенә куелган тамгалы таш. 1924 нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ میڭن جامال گه رای [قزی] ۞ ۱۹۲۴ ۞

№ 34

Шәйхеддин каберенә куелган таш. 1931 нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ [مینگی شاه] اوعلی شیح الدتن ۞ ۱۹۳۱ یلده وفات ۞

№ 35

Хәтимә Гаяз кызы каберенә куелган тамгалы таш. 1936 нче ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ عایاز قزئ حه تیمه ئولدئ ۞ ۱۹۳۶نچئ یلنگ ۱۲ نچئ سینته برنده ۞

№36

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, 1936 ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

№ 37

[**Мөхәммәдгази Мөхәммәдәмин**] угылы каберенә куелган таш. 1939 нчы ел. Акбаш авылы, 2 нче зират.

۞ وافاط ۱۹۳۹ ۞ [محمد عازی محمد امین ئوعلی [نویابرنك ۱۶ ...] ۞

№38

Хәйретдин Фаттах улы Фаттахов каберенә куелган таш. 1943 нче ел. Ак Юл авылы. Кятиб Заһид Инсаф улы Фәттахов (1951-2005).

№39

Фатыйма Хәсәншаһ кызы каберенә куелган таш. 1900-05.05.1954. Ак Юл авылы. Ире – Һадый, 1897-1962.

Сул ягында (уйма язулы):

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ حسن شاه قزى فاطيمه

№40

Шакир Вильданов каберенә куелган таш. 1869-1955. Ак Юл авылы.

№41

Хәтимә Сарым кызы Габидуллина каберенә куелган таш. 1883-1959. Ак Юл авылы.

№42

Сал[яхед]дин Сиражеддин угылы Сираев каберенә куелган таш. 10.06.1902-23.08.1963. Ак Юл авылы.

№43

Зарига Вафа кызы каберенә куелган таш. ?-16.10.1965. Ак Юл авылы.

№44

Хөсникамал Вильданова каберенә куелган таш. 1872-1967. Ак Юл авылы.

№45

Мәгъсүм Хәкимова каберенә куелган таш. 1937-?. Ак Юл авылы.

№ 46

Кемнең каберенә куелганы төгәл билгесез, язуы җуелган таш. ?-1848. Әбсәләм авылы.

Алгы ягында (калку язулы):

Текст		Транслитерация
تاريخ منكده	1	тарих меңдә

سكز يوز	2	сигез йөз
۴۸ نچى يلنده	3	48 нче йылында
عبد ال... عبد ...	4	Габдел-... Габдел....
اوعلى ... ياشنده	5	угылы ... яшендә

№47.

Кемнең каберенә куелганы төгәл билгесез, язуы җуелган таш. 1881-1953. Әбсәләм авылы.

Сул ягында (уйма язулы):

۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ ... قزىُ 1881 نچىُ جوُلدا توعان 1953 نچىُ جوُلدا ائولده.

№ 48. Кемнең каберенә куелганы төгәл билгесез. Әбсәләм авылы.

Алгы ягында (калку язулы):

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ قال ح... الموة ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله يا واقفًا بقبرى ۞

№ 49. Кемнең каберенә куелганы төгәл билгесез. Әбсәләм авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ قال ح... الموة ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله يا واقفًا بقبرى... ۞

№ 50. **Г[айшә]** каберенә куелган таш (фрагмент). Әбсәләм авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ببى [عائشه]... ۞

№ 51. **Гыйльфан** каберенә куелган тамгалы таш. Әбсәләм авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم... ۞ عيلفان ... اوعلى

№ 52. **Миңнекамал** Муллагали кызы Мөхәммәдиева каберенә куелган таш, 13.06.1887-08.08.1983. Әбсәләм авылы.

№ 53. Кемнең каберенә куелганы төгәл билгесез, 1937 ел. Әбсәләм авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ١٩٣٧ ... ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ... ۞

№ 54. **Шәр...җәмал** Бәдриҗиһан җәмәгате каберенә куелган таш. Әбсәләм авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ١٩٣٧ وفات بدرجهان جماعتى شر... جمال ۞ لا اله الا الله [محمد رسول الله]... ۞

№ 55. **Сәлимҗан** Сафиулла угылы Галимов каберенә куелган таш, 17.07.1926-23.08.1962. Әбсәләм авылы.

№ 56. **Фархури** Баһенән кызы Шәмседдинова каберенә куелган таш, 1910-13.11.1963. Әбсәләм авылы.

№ 57. “Бу таш Әбсәләм авылына нигез салучы әби-бабаларыбыз рухына багышлап куела. Июль 2023 ел”. Әлекке мәчет биләмәсендә урнашкан ташъязма истәлек.

№ 58. Бәйрәкә авылы мәдрәсәләренең сакланып калган таш биналары.

№ 59.

Йосыф Котлыгмөхәммәд угылы каберенә куелган таш, 1773 ел. Бәйрәкә авылы[3].

Алгы ягында (уйма язулы):

Текст		Транслитерация
....	1-5	....

[3] Кара: *Закиров Ә.Ә, Закирова М.Н., Хаҗиева Ә.Х.* Бәйрәкә: тарих, мәгърифәт, шәхесләр – Казан: “Школа” редакция-нәшрият үзәге, 2020. – Б. 40-42.

تاريخ مسحيه ايله	6	тарих мәсихия илә
١٧٧٣ يلده مرزه يوسف	7	1773 йылда морза Йосыф
قوتلوغ محمد اوعلى	8	Котлугмөхәммәд углы
شهد شهيد شربتن نوش	9	шәhәдән шәhид ширбәтен нуш
قيلب ٥٥ عمر كچروب دار فنادين	10	кылыб[4] 55 гомер кичереб дарелфәнадин
دار بقايه رحلت قيلدى	11	дарелбәкая рихләт кылды

№ 60

Мулла Гобәйдулла бине Ибраhим каберенә куелган таш, 1845 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Текст		Транслитерация
كفى بالموت واعظاً قد انتقل الى	1	*Кәфә бил-мәүти вагыйзән*[5] кадд интикал ила
جوار رحمة الله الامام داملا عبيد الله بن	2	җәвар рәхмәтуллаhи[6] әл-имам дамулла Гобәйдулла бине
ابراهيم سنة حمسن و ربعين و ثمانمأة و الف	3	Ибраhим сәнәти хәмсин вә рәбигыйн вә сәманмиәт вә өлеф[7]
طاب الله ثراه و جعل الجنة مثواه فما حسن ما قيل من لسان حال التوفى شعر	4	таййәбә Аллаhу сәраhу вә җәгаләл-җәннәти мәсваhу[8] фәма әхсән ма кыл мин лисан халь әт-мөтәваффи, шигырь
يَا وقفًا بقبرى متفكرًا بامرى بالامسى كنت مثلك	5	Йа вакыйфән би-кабри

[4] *Шәhәдән шәhид ширбәтен нуш кылыб* – Шәhид булып үлем ширбәтен эчеп (вафат).

[5] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* - Үлем – зирәк укытучы.

[6] Кадд интикал ила җәвар рәхмәтуллаhи – Ул (мәрхүм) Аллаh шәфкатенә күчте.
[7] *Сәнәти хәмсин вә рәбигыйн вә сәманмиәт вә өлеф* – Бер мең сигез йөз кырык бишенче ел.
[8] *Таййәбә Аллаhу сәраhу вә җәгаләл-җәннәти мәсваhу* – Аллаh туфрагын яхшы итсен hәм актык урынын җәннәт кылсын.

		мөтәфәккирән би-әмр бил-әмси күнтү мисликә,
غدا تصير مثلى	6	бил-әмси күнтү мисликә, гадән тәсайир мисли[9] .

№ 61-1. Кемнең каберенә куелганы төгәл билгесез, язуы җуелган таш. Бәйрәкә авылы.

№ 61-2 (Кара: № 64)

Хәсән мулла Муса угылы каберенә куелган таш, 1867 ел. Бәйрәкә авылы.

№ 62.

Галимә бинте Әхмәдкәрим, Габделгали бине Габидулла хатыны каберенә куелган таш, 1887 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма һәм калку язулы):

Текст		Транслитерация
لا اله الا الله محمد رسول الله	1	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ*
اوشبو مَقبرَه دَه زوْج	2	ошбу мәкъбәрәдә зәүҗе[10]
عَبد العَلى [بن] عَبيد الله عليمه بنت	3	Габделгали бине Габидулла, Галимә бинте
احمد كريم بن قربانعلى ٥١ ياش	4	Әхмәдкәрим бине Корбангали 51 яшь
عُمر سرب و ١٣٠٥ سنهء هجريّه ده	5	гомер сөреб вә 1305 сәнә һиҗриядә

[9] *Йа вакыйфән би-кабри, мөтәфәккирән би әмри, бил-әмси күнтү мисликә, гадән тәсайир мисли* – Әй, каберем янына килеп басучы, минем хәлне фикерлә; бүген син шул хәлеңдә булсаң, иртәгә минем кебек булырсың.

[10] Зәүҗе – (Габделгали бине Габидулланың) хатыны.

دفن قلنمُش در	6	дәфен кылынмышдыр
نور الله مرقدُها آمین	7	нәүвәрә Аллаһу мәркадиһа, [11] амин

№ 63. Кемнең каберенә куелганы төгәл билгесез, язуы өлешчә җуелган таш. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ اعوذ بالله من الشیطان الرجیم ۞ بسم الله الرحمن الرحیم... ۞ ... ۱۸۹۰ نچی یلده ۞

№ 64

Бибигайшә мулла Гобәйдулла кызы каберенә куелган таш, 1891 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشیطان الرجیم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِیمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ اشهدان لا اله الا الله و ۞ و اشهدان محمد عبده و رسوله ۞ اتکامز حسن ملا موسی اوعلی ۞ مرحوم ۱۸۶۷ نچی یلده ۞ اپریل ننک ۱۹ یومنده ۞ انکامز ببی عیشه ملا عبید الله ۞ قزی مرحومه ۱۸۹۱ نچی یلده ۞ سنتبراننک ۳۰ یومنده ۞

№ 65

Исхак бине Муса угылы каберенә куелган таш, 1895 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (калку язулы):

Текст		Транслитерация
کل نفس ذائقة	1	*Көллү нәфсин заикател-*
الموت ثم الینا تر جعون	2	*мәүт сөммә иләйнә түрҗәгунә*[12]

[11] Нәүвәрә Аллаһу мәркадиһа – Аллаһ каберен нурландырсын.

هذا مرقد شريف	3	һазә мәркадь шәриф[13]
اسحاق بن موسى	4	Исхак бине Муса
دار فنادان	5	дарелфәнадән
داربقایه رحلت	6	дарелбәкая рихләт
قیلدی تاریخ مسیحیَّه	7	кылды тарих мәсихийә
ایله١٨٩٥ سنه ده مارط	8	илә 1895 сәнәдә март-
ننک ۶ نچی کوننده یاشی	9	-ның 6 нчы көнендә
۶٣ یاشنده	10	63 яшендә

№ 66

Мулла Сәлимҗан бине Гобәйдулла каберенә куелган таш, 1824-1896. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (калку язулы):

Текст		Транслитерация
کفی بالموت واعظا	1	*Кәфә бил-мәүти вагыйзән*
الحکم لله العلی الکبیر هوَ الحَی	2	*Әл-хөкме лилләһи әл-Гали әл-Кәбир,*[14] *һу әл-хәййе*
الذی لا یموت قال رسول	3	*әл-ләзи ля-йәмүт*[15] калә рәсүл
الله صلی الله علیه و سلم	4	Аллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм[16]

[12] *Көллү нәфсин заикател-мәүт сөммә иләйнә түрҗәгунә* – Әлбәттә, үлем ачысын һәркем татыячактыр, соңра кубарылып, Миңа кайтырсыз. (29 нчы сүрә "Ганкабут", 57нче аят**).**

[13] Һазә мәркадь шәриф – бу игътибарга лаек кабер.
[14] Әл-хөкме лилләһи әл-Гали әл-Кәбир – Хөкем итү Бөек, Олуг Аллаһ карамагындадыр.

[15] Һу әл-хәййе әл-ләзи ля-йәмүт – Ул (Аллаһ) мәңге үлемсез (25 сүрә “әл-Фуркан”, 58 аять).
[16] Калә рәсүл Аллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм – Әйтте Аллаһның илчесе (аңа Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын).

القبر روضة من رياض الجنة	5	әл-кабрү раудәт мин рийадил-җәннәт[17]
او حفرة من [النيران] اللهم	6	әү хофрәт мин [хәфрән]-нәйран[18], Аллаһүммә
اجعل قبر هذ المت من	7	әҗәгаль кабри һәзаль-мәйти мин
رياض الجنة مرقد شريف	8	рийадил-җәннәт мәркадь шәриф[19]
ملّاَ سلم جان بن عبيد الله	9	мулла Сәлимҗан бине Гобәйдулла
ولد رحمة الله ۱۸۲۴	10	вәләд Рәхмәтулла[20] 1824
سنهء ۱۸۹۶ چوپای قريسنک	11	сәнәи 1896 Чупай карьясенең
كتبه ضيأ الدين بن	12	кәтибәһе Зыяддин бине
حسام الدين چوپای	13	Хисамеддин Чупай
قريسنک	14	карьясенең[21]

Чупай карьясендә гомер кичергән кятиб Зыяддин бине Хисамеддин. Бу авыл янәшәсендә тирә-якка мәгълүм булган таш карьеры бар.

№ 67

...җәмал ... җәмәгате каберенә куелган таш, 1897 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ [لا اله الا الله محمد رسول الله] ۞ ... جمال مم... [جما]عتى ۱۸۹۷ نچى [يلده] سينتبر ننک ۱۰ نچى [كوننده] ... ۞

№ 68

[17] әл-Кабрү раудәт мин рийадил-җәннәт – [Аллаһ] каберен җәннәт бакчасы [кылсын].
[18] Әү хофрәт мин [хәфрән]-нәйран – [Аллаһ] җәһәннәм чокырыннан сакласын.
[19] Аллаһүммә әҗәгаль кабри һәзаль-мәйти рийадил-җәннәт мәркадь шәриф – Илаһым, бу мәетнең каберен җәннәт бакчасы кыл.
[20] Вәләд Рәхмәтулла – Рәхмәтулланың оныгы.
[21] Чупай карьясендә гомер кичергән кятиб Зыяддин бине Хисамеддин. Бу авыл янәшәсендә тирә-якка мәгълүм булган таш карьеры бар.

Бибинәфисә, Габделхалик аганың җәмәгате каберенә куелган таш, 1897 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... اوشبو ...مقبره ده مدفونه عبد الحالق آعا جماعتی بی بی نفیسه در وفاتی
... ۱۸۹۷ ۞ نوّر الله مرقد ها ۞

№ 69

Мөхәммәдгали кызы каберенә куелган таш, 1897 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد
رسول الله ۞ اوشون یلده ۳ ... محمد علی قزی ۱۸۹۷ نچی جلده ... ۞

№ 70

... Мөхәммәд... Мөхәммәдсафа угылының җәмәгате каберенә куелган таш, 1898 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... ۞ ... راحیم قزی ۞[محمد ... محمد صفا اوعلی ننک ۞ جماعتی وفات
بولدی ۞ ۱۸۹۸ نچیلده [۱۴] نچی سینت... ۞ ... ۞

№ 71

Мөхәммәдҗан Габдел**...** [угылы] каберенә куелган таш, 1899 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ وفات بولدی محمد جان عبد ال... ۞ ۱۸۹۹ ۞

№ 72

Габделгали шәех, мөдәррис, бине Габдулла бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви каберенә куелган таш, 1901 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ الحكم لله العزيز المتعال ۞ هذه المرقد الشيخ المدرسْ ۞ عَبد العَلى بن عبد الله بن ابراهيم البيركاوى تولد فى ١٢٣٨ سنه ۞ و توفى ١٣١٩ بعْد الهجرة ۞ النبوية بعْد تدريسه سبعه و حمسين ۞ سَنة نوّر الله مَرقده ۞ الشريف آمين ۞

№ 73

М[өхәммәдхафиз] бине Мөхәммәдвәли бине Гомәр каберенә куелган таш, 1364 сәнәдә 1944 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... ۞ ... ۞ محمد حافظ بن محمد ولى ۞ بن عمر ۶۳ ياش ۞ عمر ...۱۳۶۴ ۞ سنهء هجريّه دفن ... ۞ نور الله مرقد ۞ آمين ۞

№ 74

Фәрхиҗиһан Габдеррахман кызы каберенә куелган таш, 1906 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ۱۹۰۶ نچى يلده سينتابرننک ۲۰ کوننده وفات بولدى ۞ فرح جهان ۞ عبد الرحمن ۞ قزى ۞

№ 76

Кемнең каберенә куелганы төгәл билгесез, язуы өлешчә җуелган таш. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ ... ۞

№ 77

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Бәйрәкә авылы.

№ 78

Бибифатыйма Фәс... кызы каберенә куелган таш. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ دار فناد دار بقايه رحلت قيلاند... ۞ ببى فاطما فسع اللس... قزى ۞

№ 79

Мөхәммәдсадыйк Габд[улла] угылы каберенә куелган таш. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... ۞ كل من عليهافان ويبقى وجه ربك ۞ مرحوم محمد صاديق عبد [الله اوعلى ۸۴ ياشنده وفات ... الله تعالى رحمتنده بولسون ۞

Көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһү Раббикә Зөл-Җәлали вәл-икрами (Коръәннең “Рахман” сүрәсендәге 26-27 аятьләрдән алынган).

№ 80

Мөхәммәдсадыйк Габд[улла] угылы каберенә куелган таш. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ اشهدان لا اله الاالله و اشهدان محمدا عبده و رسوله ۞ كل من عليهافان ويبقى وجه ربك ۞ ذوالجلال و الاكرام الحكم الله الكبير ۞ كل نفس ذائقة الموت ۞ ۱۹۱۰ نچى يلنده آعوسننک ۸ كوننده هجرة ... مرحوم احمد [خلفه] محمد... ۞ .... ۞

Әшһәду әл-лә иләһә иллә Аллаһу вә әшһәду әннә Мүхәммәдән габдүһү вә расүлүһә[22]
[1] Кәлимәи шәһадәт: бер Аллаһтан башка илаһи зат юклыгын һәм Мөхәммәд аның илчесе булуын таныйм.

Көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһү Раббикә зөл-Җәлали вәл-Икрами – Җирдә булган бар нәрсә һәлак булачак. Фәкать олуглык һәм хөрмәт иясе булган Раббыңның заты мәңгелек.

الحكم لله العلى الكبير Хөкем итү Бөек, Олуг Аллаһ карамагындадыр.

كل نفس ذائقة الموت *Көлли нәфсин заикател-мәут* – Һәрбер җан үлем тәмен татып караячак.

№ 81

[22] Кәлимәи шәһадәт: бер Аллаһтан башка илаһи зат юклыгын һәм Мөхәммәд аның илчесе булуын таныйм.

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. Бәйрәкә авылы.

№ 82

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشیطان الرجیم ۞ ... ۱۹۱۴ ... ۞

№ 83

Х[әниф Мөхәммәдшәриф угылы] каберенә куелган таш. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ [۱۸۱۴] نچی یلده توعان ۞ اعوذ بالله من الشیطان الرجیم ۞ بسم الله
الرحمن الرحیم ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ اشهدان لا اله الاالله و اشهد۞
ان محمدا عبده و رسوله ۞ ۱۹۱۲ نچی یلده طبدی حنیف محمد شریف ۞

№ 84

Ярулла мулла, бине Фазулла әл-Бәйрәкәви каберенә куелган таш. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ کل نفس ذائقة الموت ۞ هذا المرقد ملا یار الله بن فض الله البیرَکاوی تولد
فی ۱۸۴۰ سنهء و مات فی ۱۹۱۲ سنة المیلادیه نور الله مرقده ۞

№ 85

Гамилә, мулла Хөсәен кызы каберенә куелган таш. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ [...۱۸] نویابر[ننک ۲] کوننده وفات بولدی عامیله ملا حسین قزی ۞

№ 86

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. Бәйрәкә авылы.

№ 87

Шәмсекамәр, мулла Мөхәммәдгази кызы каберенә куелган таш, 1919 ел. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ الله الحيى و يميت ۞ و حى ... يموت ۞ شمس قمار ملا محمد عازى ۱۹۱۹
سنة ۱۳ ايون وفات ۞

№ 88-1

Бәдреддин Фәхреддин [угылы] каберенә куелган таш, 1921. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ كل من عليهافان
ويبقى وجه ربك ۞ ذوالجلال و الاكرام الحكم الله الكبير ۞ اشهدان لا اله الا الله
و اشهدان محمد عبده و رسوله ۞ ۱۹۲۱ يلده ۶ فيبرال متوفى مرحوم بدر الدين
فحر الدين ۷۸ ياشنده دار الفنادن دار... ۞

№ 88-2

Шәмаил. Бәйрәкә авылы.

№ 89

Хөсникамал бинте Корбангали каберенә куелган таш, 1941. Бәйрәкә авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ۱۹۴۱ نچى يل ۸ نويابر۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بسم الله
الرحمن الرحيم۞ كل من عليهافان ويبقى وجه ربك ۞ ذوالجلال و الاكرام الحكم
الله الكبير ... ۞ حسنى كمال بنت قربانعلى ۞

№ 90

Фатыйх Зариф угылы Шәрипов, Советлар Союзы герое истәлегенә куелган таш, 20.01.1921-29.06.1995. Бәйрәкә авылы.

№ 91

Балтач бине Дусбай каберенә куелган таш. Дим-Тамак авылы.

Ташъязмада борынгыдан килгән төрки исемнәр уеп язылган. Бу ядкәр XIX яисә, XVIII гасырларга карыйдыр дип фараз ителә.

Алгы ягында (уйма язулы):

Текст		Транслитерация
لا اله الا الله محمد رسول الله	1	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ*
بالطاچ بن	2	Балтач бине
دوصبای	3	Дусбай

№ 92

Исеме билгесез хатын-кызның каберенә куелган таш, язулары җуелган. Дим-Тамак авылы.

№ 93

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. 1885 ел. Дим-Тамак авылы.

Алгы ягында (уйма язулы)

۞ ... ۞ ۱۸۸۵ ... ۞ المرحوم ... ۞ ... ۞

№ 94

Мөхәммәдсадыйк каберенә куелган таш. 1888 ел. Дим-Тамак авылы.

Алгы ягында (уйма язулы)

Текст		Транслитерация
لا اله الا الله محمد رسول الله	1	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ*
صاحيب هده القبور	2	сахиб һазә әл-кабер
محمد صاديق	3	Мөхәммәдсадыйк

كاتب على	4	Кятиб Гали
١٨٨٨ يلده	5	1888 йылда

№ 95

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. Дим-Тамак авылы.

Алгы ягында (уйма язулы)

۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ ... ۞

№ 96

С[өләйман] каберенә куелган таш, 20.01.1921-29.06.1995. Дим-Тамак авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ [سليمان] ... ۞

№ 97

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. Дим-Тамак авылы.

№ 98

Хәйрулла Вәлиулла угылы каберенә куелган таш, 1910 ел. Дим-Тамак авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ... ۞ هذا صاحب [القبر] خير الله ولى الله اوعلى ١٩١٠ نچى يلده اپريل ننک ... ۞

№ 99

Сәрвиҗиһан каберенә куелган таш, 1951 ел. Дим-Тамак авылы.

Кятиб мәрхүмәнең улы – Хәляфеддин.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... ۞ سرو جهان ... ۞ اوعلی حلاف الدین یاز[د]ی 1951 ۞

№ 100

Миннеязкәр Сабир улы Шакиров каберенә куелган таш, 04.06.1937-07.12.2021. Дим-Тамак авылы.

№ 101

Казан губернасының Алат юлындагы Морзалар Ырысының Муса бине мулла Габделҗәлил ... углының кызы **Зөһрә** каберенә куелган таш, 1767 ел. Иске Ырыссу авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Текст		Транслитерация
تاریخ منکدا یوزده	1	тарих меңдә йөздә
سکسان برنچی	2	сиксән беренче
یلنینک اچندا ایردی	3	йылының [эчендә] ирде
جمادل الا خر ایندا قزان ایوزینک	4	җомадиәл-ахыр аенда Казан өязенең
آلاط یولنک مرضالار اوروسینک	5	Алат юлының Морзалар Ырысының
موسی بن ملا عبد الجلیل مر...تلی	6	Муса бине мулла Габделҗәлил Мор...тлы
اوغلینک قزی زهرا قبردور	7	углының кызы Зөһрә кабередер

№102

Әхмәр бине Габделмәннан (бине Юрткә бине Ютәбай бине Кол бине Килдеш бине Дәүләҗар бине Имин бине Байтәүкәл бине Илүс бине Әлкәш) каберенә куелган тамгалы таш. 1772 нче ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират. Кара: *Фәхретдинов Ризаэддин.* Асар. 2 том – Казан: Рухият, 2009. – Б.104-105.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ احمر بن عبد المنان ۞ وفاتی تاریخ ۱۷۷۲ ۞

№103

Әбүбәкер бине Мөхәммәдрәхим бине Ибраһим каберенә куелган тамгалы таш. 1785 ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ [۱۲۰۰] سنه ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله صلى الله ۞ عليه و سلم كل نفس ذائقة الموت ۞ [۱۲۰۰] سنهابو بكر بن محمد رحيم بن ابراهيم [منكرى] وفات بولدى ۞

№104

К[асыйм] бине Әхмәр каберенә куелган тамгалы таш. 1787 ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ تاريخ وفات ۞ [قا]سيم بن احمر ۞

№105

Бибихәбибә бинте Мостафа каберенә куелган тамгалы таш. 1795 ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ [تاريخ روميه] ۞ ۱۷۹۵ ۞ بيبى [حبيبه] بنت ۞ مصطفا ۞

№106

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Иске Ырыссу авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... ۞ ياشى دورت ۞ وافات ۞

۞ ...۞... ۞ яше дүрт ۞ вафат ۞

№107-1

Гобәйдулла бине Рафик каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы, 1803 ел.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ۱۸۰۳ سنه ۞ عبيد الله ۞ بن ۞ رفيق ۞

۞ 1803 сәнә ۞ Гобәйдулла ۞ бине ۞ Рафик ۞

№107-2

Нәзирә Әхмәр кызы каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы, 1803 ел.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ تاريخ اوروص حيصابى ۞ ايلان ١٨٠٣ يلده آست يو ۞ لدوزوننک آوّلنده ماهى رابيغ آوّ۞ لنده وفات اولدى نزيره آحمر ۞ [قزي] اوتوز سيكز ياشده ايردى ۞

№108

Г[абделбәшир] Бакый угылы каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы, 1808 ел.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ الحکم لله ۞ ١٨٠٨ سنه نچى يلده ربيع الاول ننک اخر ... [عبد البشير] باقى اوعلى [وفات بولدى] ۞

№109-1

Монасиб Мортаза угылы каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы, 1833 ел.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ تاريخ ١٨٥١ ۞ محيبه اطنال قزى ۞ ١٨٣٣ مناسب مرتضا اوعلى ۞

№109-2

Мөхибә Атна[го]л кызы каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы, 1851 ел.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ تاريخ ١٨٥١ ۞ محيبه اطنال قزى ۞ ١٨٣٣ مناسب مرتضا اوعلى ۞

№ 110

Казан сәүдәгәре Мөхәммәдшәриф Габделмәҗид углының кызы **Хәйрелбанат** каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы. 1874 ел.

Алгы ягында (калку язулы):

Текст		Транслитерация
مقبرءی	1	мәкъбәрәи
ملا عبد الحکیم	2	мулла Габделхәким
[قزان] سودکاری	3	[Казан] сәүдәгәре
محمد شریف	4	Мөхәммәдшәриф
عبد المجید اوعلی	5	Габделмәҗид углы-
ننک قزی حیر البنات	6	-ның кызы Хәйрелбәнат
وفات بولدی ۱۸۷۴ نچی	7	вафат булды 1874 нче
....	8	....

№111

Мөхибә Атна[го]л кызы каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы, 1851 ел.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ کفی بالموت واعظا ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ ۱۸۸۰ نچی یلده ایون ۷ ...
۞ وفات [بولدی] عبد الولی [ابن بلال] ... ۞

Кәфә бил-мәүти вагыйзән - Үлем – зирәк укытучы.

№112

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. 1882 ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... ۞ ۱۸۸۲... ۞ ... ۞

№ 113

Хөснежәмал Биккенә кызы, Әхмәдшаһ мулла угылының хәляле каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы. 1883 ел.

Алгы ягында (калку язулы):

Текст		Транслитерация

توفی فحر الدین مناسب	1	тәүвәффи Фәхреддин Монасиб
اوعلی تاریخ [عیسي] ... و	2	углы тарих [Гайса] ....
ایله ۱۸۸۳ سنه ده	3	илә 1883 сәнәдә
مارط ننک ۱۰ نچی کوننده	4	мартның 10 нчы көнендә
عمری ۶۸ یاشده	5	гомере 68 яшьдә

№ 114

Габдулла бине Әхмәдшаһ бине Ибраһим каберенә куелган таш, 1901 ел. Иске Ырыссу авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... ۞ ۱۸۸۳ نچی یلده اوکتابر ننک ۴ ده وفات اولدی حسنی جمال بیککنه قزی احمد شاه ملا محمد امین المرحوم اوعلی ننک حلال جفتی ۞ رحمتو الله علیه رحمة واسعةً امین یا رب العالمین ... ۞

№115

Кемнең каберенә куелганы билгесез тамгалы таш. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

№116

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

№117

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

№ 118

Мөхәммәд[йосыф][23] бине Әхмәдшаһ бине Ибраһим каберенә куелган таш, 1889 ел. Иске Ырыссу авылы.

Алгы ягында (калку язулы):

۞ توفی [محمد ... ف] ۞ [ابن ... سنه] ۞ بتاریخ [مسحیه ۱۸۸۹] ایون ننک ۱۰ نچی یومنده اوکتابرده ۞

№ 119

[23] Бәлки, “Мөхәммәдгариф” дип укыладыр.

Мөхәмәджан Габделкәрим угылы каберенә куелган таш, 1891 ел. Иске Ырыссу авылы.

Алгы ягында (калку язулы):

۞ توفى محمد جان عبد الكريم اوعلى تاريخ [روميه ايله] ١٨٩١ ... ٢١ نچى ۞

№ 120

Бибигайшә Рәхимкол кызы каберенә куелган таш, 1892 ел. Иске Ырыссу авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ١٨٩٢ نچى يلده وفات ۞ ببى عيشه رحيم قل قزى ۞

№ 121

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары начар хәлдә сакланган. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ ... نچى يلده وفات ۞

№ 122

Мөхәммәдшәриф [Габделләтыйф] угылы каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ [عبد اللطيف اوعلى محمد شريف] ۞

№ 123

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган һәм бик начар хәлдә сакланган. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

№ 124

Габдулла бине Әхмәдшаһ бине Ибраһим каберенә куелган таш, 1901 ел. Иске Ырыссу авылы.

Алгы ягында (уйма язулы):

Текст		Транслитерация
۱۹۰۱ یلده ۳۰ نچی مارط ده	1	1901 йылда 30 нчы март да
بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ	2	*Бисмиллаһир ир-рахман ир-рахим*[24]
دارفنادان داربقایه رحلت قلدی	3	дарелфәнадән дарелбәкая рихләт кылды
وفات مرحوم عبد الله ابن	4	вафат мәрхүм Габдулла ибне
احمد شه بن ملّا محمد	5	Әхмәдшаһ бине мулла Мөхәммәд-
امین بن ابراهیم رحمت الله	6	-әмин бине Ибраһим рәхмәтуллаһи
تعالی رحمتً واسعتً	7	Тәгаләә рәхмәтән васыйгатән
.... آمین	8	.... амин

№ 125

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш (фрагмент), язулары җуелган. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... ۞ [۱۸...] یلده ۞

№ 126

Шәмсениса каберенә куелган таш, 1901 ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

[24] *Бисмиллаһир ир-рахман ир-рахим* – рәхимле, шәфкатле Аллаһның исеме белән.

۞ ۱۹۰۱ نچی یلده عینوارننک ۲ نچی کوننده [وفات] بولدی شمسنسه ... قزی ... ۞

№ 128

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ ... ۱۹۰۴ نچی ... اوعلی ... ۞ ... امین ۞

№ 129

Мөхәммәд[җан] бине Шаһиәхмәд бине Габделхәлим бине Әбүбәкер каберенә куелган таш, 1904 ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ کفی بالموت واعظا ۞ ... ۱۹۰۴ نچی سنه ده ۞ متوفی ... مرحوم محمد [جان] بن شاهی احمد بن عبد الحلم بن ابو بکر [دار فنادان] دار بقایا ... ۞

№ 130

Гайшә Мөхәммәд хатыны каберенә куелган таш, 1916 ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ۱۹۱۶ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ... ۞ وفات اولمش عائشه محمد حلالی فیبرال ننک ۱۴ ۞

№ 131

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма һәм калку язулы):

۞ کفی بالموت واعظا ۞ ... ۞

№ 132

[Шаһи] кызы каберенә куелган таш.   Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ اعوذ بالله من الشيطان الرجيم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ ... ۞ ... شاهی قزی ... ۞

№ 133

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ... ۞ تاریخ ... ۱۹۰۷ ... [متوفی... اوعلی بیراکی...] ۞

№ 134

Мөхәммәдгали бине Мөхәммәдрәхим бине Ибраһим каберенә куелган таш. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ۞ کل نفس ذائقة الموت ۞ محمد علی بن محمد رحیم بن ابراهیم ۞

№ 135

Кемнең каберенә куелганы билгесез таш, язулары җуелган. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ تاریخ بالمسحیه [۱۹۱۱ نچی سنه ده ۳] نچی ... ۞

№ 136

[Хөббениса] Габделмәннан җәмәгате каберенә куелган таш, 1911 ел.   Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ ۱۹۱۱ نچی یلده فیبرال ننک ۲۱ نچی ۞ اعوذ بالله من الشیطان الرجیم ۞ بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ۞ [حبنسا]عبد المنان جماعتی ۞

№ 137

[Хөббениса] Габделмәннан каберенә куелган таш, 1911 ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ... ۞... ۱۹۱۳ مارط ۲۲ نچی وفات ۞ اولدی اوغلی ... ۞

№ 138

Б[ану Габделмәннан угылы] каберенә куелган таш, 1912[25] ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма язулы):

۞ لا اله الا الله محمد رسول الله ... ۞... ۱۹۱۲ ... وفات [بولدی] ... بانو عبد النان ... ۞

№ 139

Мөхәммәдзариф ибне Гомәр ибне [Мортаза] каберенә куелган таш, [1900] ел. Иске Ырыссу авылы, 1 нче зират.

Алгы ягында (уйма һәм калку язулы):

